РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » 10 2024 ел №923

2024 елның IV кварталына
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы буенча
торак мәйданының 1 квадрат метрының
уртача базар бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 санлы карары белән расланган "2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" дәүләт программасының "2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү" ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" муниципаль программасын раслау турында"гы 2020 елның 11 декабрендәге 865 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. 2024 елның IV кварталына Ютазы муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен (сумнарда) федераль бюджет акчалары исәбеннән гражданнар категорияләре өчен социаль түләүләр күләмнәрен исәпләү өчен 40 571 (кырык мең биш йөз җитмеш бер) сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
2-42-05